СОВЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 13 апреле** Болгар ш **№ 8-4**

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2016 елның 30 мартындагы 6-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 12 февралендәге ПУ-132 номерлы Указын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнарында һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын алып бару эшчәнлеген камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2016 елның 30 мартындагы 6-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 5 пунктында “шулай ук кәгазьдә” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2 бүлекнең беренче абзацында “һәм кәгазь чыганакта” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 2 бүлекнең 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. 2 бүлекнең 4 пунктындагы икенче абзацында “атасының исемен” сүзеннән соң "(булган очракта)";

4 бүлекнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Муниципаль органнарда муниципаль хезмәткәрләр реестры, аларга үзгәрешләр Мәгълүмати системада саклана, анда булган мәгълүматны рөхсәтсез файдаланудан, юкка чыгарудан, модификацияләүдән, блоклаудан, күчерүдән, күрсәтүдән, таратудан, шулай ук башка төрле хокук булмаган гамәлләрдән яклауны тәэмин итеп."

1.6. 3 һәм 4 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

Спас муниципаль районы Советы башлыгы,
Совет рәисе Ф.В. Мөхәммәтов